# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлегенең Өчиле-Саклау авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**от 28.03.2024 г.** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә , «Саклаубаш авыл җирлеге Өчиле Саклауторак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 7 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең Өчиле Саклауторак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 7 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең Өчиле Саклауторак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында» Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 18 мартындагы 2 номерлы карары нигезендә 2024 елның 28 мартында 14.00 сәгатьтә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән сораулар буенча гражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Саклаубаш авыл җирлеге Өчиле Саклау торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 7 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең Өчиле Саклауторак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 7 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарларына чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) Өчиле Саклау торак пунктына урам яктырту челтәрләрен ясау.

2) Төзелеш материаллары сатып алу һәм су башнясына койма тоту

3) Торак пункт территориясен төзекләндерү өчен МТЗ-82.1 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү);

4) Халыкара хатын-кызлар көне, Җиңү көне, сабантуй, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, Өчиле-Саклау торак пунктында төрле чаралар үткәрү өчен бүләкләр, алу;?

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган _130__ кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - _91___ кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен _91___катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен ____0___ катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Саклаубаш авыл жирлегенең Өчиле-Саклау авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2024 елда 300 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Саклаубаш авыл җирлеге Өчиле-Саклау аылы территориясендә I төркем

инвалидлардан; хәрби хезмәт үтүчеләрдән; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча Өчиле-Саклау авылында теркәлгән һәр балигъ булган һәрбер кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өсен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

1) Өчиле Саклау торак пунктына урам яктырту челтәрләрен ясау.

2) Төзелеш материаллары сатып алу һәм су башнясына койма тоту

3) автомобиль юлларын карап тору өчен МТЗ-82.1 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү);

4) Халыкара хатын-кызлар көне, Җиңү көне, сабантуй, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, Өчиле-Саклау торак пунктында төрле чаралар үткәрү өчен бүләкләр, алу;

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Саклаубаш авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Саклаубаш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче Л.М.Габидуллина